**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Иске Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Яңа Чүпрәле авылында гражданнар җыены**

# КАРАРЫ

**27 нче ноябрь 2020 ел** **Яңа Чүпрәле** **№1**

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы “Иске Чүпрәле авыл җирлеге " муниципаль берәмлегендә Яңа Чүпрәле авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 октябрендәге 59/3 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмә, 2020 елның 27 ноябрендә тавыш бирү йомгаклары турында, 2020 елның 27 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә, тавыш бирү тәмамланган вакытта, җыенда катнашучы 868 кеше кертелгән, гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирүдә катнашкан саны-461, бу исемлеккә кертелгән гражданнарның 53,11 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 461 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, бу гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучыларның 100% ын тәшкил итә; «Каршы» позициясе өчен, җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде, бу 0 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә карар иттеләр:

1. 2020 елның 27 ноябрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының « Иске Чүпрәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Яңа Чүпрәле авылында гражданнар җыенын 2020 елның 27 ноябрендә уздырылган, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес дип танырга.

2."Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Яңа Чүпрәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Яңа Чүпрәле урамнарны яктырту челтәрен ремонтлау;

- Яшьләр урамы, Совет урамы, Яңа Чүпрәле авылы урам-юл челтәрен ремонтлау;

- Колхоз урамыннан алып Яңа Чүпрәле зиратына кадәр юлны ремонтлау;

- Яңа Чүпрәледә зиратларны карап тоту;

- Яңа Чүпрәле авылында иске агачларны кисү;

- Яңа Чүпрәле авылында обелиск территориясен төзекләндерү;

дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. 2021 елда Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге Яңа Чүпрәле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә.

- Яңа Чүпрәле урамнарны яктырту челтәрен ремонтлау;

- Яшьләр урамы, Совет урамы, Яңа Чүпрәле авылы урам-юл челтәрен ремонтлау;

- Колхоз урамыннан алып Яңа Чүпрәле зиратына кадәр юлны ремонтлау;

- Яңа Чүпрәледә зиратларны карап тоту;

- Яңа Чүпрәле авылында иске агачларны кисү;

- Яңа Чүпрәле авылында обелиск территориясен төзекләндерү;

4. Халык җыены нәтиҗәләрен «Туган як " газетасында бастырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы,**

**Иске Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы урынбасары,**

**халык җыенында рәислек итүче:** **Р.Д.Низамов**